ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Алексеевск ш.т.б.

29.07.2019 № 318

**Балигъ булмаган гражданнарның опекуннары яисә попечительләре булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү вәкаләтләрен гамәлгә ашыручыоешма эшчәнлеген контрольдә тоту яки, Россия Федерациясенең гаилә законнарында билгеләнгән башка формаларда, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә тәрбияләү өчен кабул итү Тәртибен раслау турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Балигъ булмаган гражданнарга карата опека һәм попечительлекне гамәлгә ашыруның аерым мәсьәләләре турында" 2009 елның 18маендагы 423 номерлы карары, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының "Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларны әзерләү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында" 2015 елның 13 мартындагы 235 номерлы боерыгының 24 пунктынигезендә

**карар бирәм:**

1. Балигъ булмаган гражданнарның опекуннары яисә попечительләре булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы оешма эшчәнлеген контрольдә тоту яки, Россия Федерациясенең гаилә законнарында билгеләнгән башка формаларда, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә тәрбияләү өчен кабул итү Тәртибен,кушымта нигезендә, расларга.
2. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны опека һәм попечительлек бүлегенә йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К. Кадыйров**

Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның29 июлендәге
318 номерлы карарына кушымта

**Балигъ булмаган гражданнарның опекуннары яисә попечительләре булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы оешма эшчәнлеген контрольдә тоту яки, Россия Федерациясенең гаилә законнарында билгеләнгән башка формаларда, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә тәрбияләү өчен кабул итү Тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге тәртип Балигъ булмаган гражданнарның опекуннары яисә попечительләре булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы оешма эшчәнлеген контрольдә тоту яки, Россия Федерациясенең гаилә законнарында билгеләнгән башка формаларда, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә тәрбияләү өчен кабул итү кагыйдәләрне билгели(алга таба Оешма).

1.2. Оешма эшчәнлеген тикшереп тору Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.3. Оешма эшчәнлеген контрольдә тоту предметы булып, гражданнарны түбәндәге критерийлар буенча сайлап алу һәм әзерләү буенча опека һәм попечительлек органы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тора:

1.3.1. Гражданнарны әзерләү буенча укыту-тематик планын үтәү.

1.3.2. Гражданнарның әзерлеген тикшерү технологияләрен куллану.

1.3.3. Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларны әзерләү дәрәҗәсенең программа таләпләренә туры килүе.

1.3.4. Гражданнарга әзерлек узу турында документ бирүнең нигезлелеге.

1.3.5. Документлар һәм хисап алып баруны анализлау.

1.4. Оешма эшчәнлеген контрольдә тотуның төп максатлары:

1.4.1. Гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча опека һәм попечительлек органы вәкаләтләрен, алар тарафыннан түләүсез нигездә, гамәлгә ашыру өлешендә оешма эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү.

1.4.2. Гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча оешма эшчәнлегендә хокук бозуларны ачыклау һәм аларны бетерү буенча тәкъдимнәр эшләү.

## 2. Тикшерү үткәрү процедурасы

2.1. Оешма эшчәнлеген тикшерү планлы һәм планнан тыш тикшерүләр үткәрү юлы белән башкарыла.

2.2. Планлы тикшерүләр елга бер тапкырдан да ким үткәрелми.

2.3. Планлы тикшерүләр үткәрү графигы Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең карары белән раслана (Тәртипкә 1 номерлы кушымта).

2.4. Планнан тыш тикшерүләр физик яки юридик затларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылуга карата шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә, документлар һәм мондый хокук бозу билгеләре булуын раслаучы башка мәгълүмат алынган очракта үткәрелә.

2.5. Планлы һәм планнан тыш тикшерүләр, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең тикшерү үткәрү турындагы күрсәтмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты опека һәм попечительлек органының вәкаләтле заты тарафыннан үткәрелә.

2.6. Тикшерү вакытында, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек органының вәкаләтле заты оешма җитәкчесеннән әзерлек узган гражданнарның һәм укучыларның шәхси эшләрен, шулай ук тикшерү үткәрү өчен кирәкле документларны, материалларны, аңлатмаларны соратып алырга хокуклы.

2.7. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек органының вәкаләтле заты гражданнарны әзерләү программасы кысаларында оешма белгечләре үткәрә торган дәресләргә (лекцияләргә, семинарларга, тренингларга) йөрергә, шулай ук әзерлек нәтиҗәләре турында гражданнарның фикерләрен өйрәнергә хокуклы.

## 3. Тикшерү үткәрү нәтиҗәләре

3.1. Тикшерү нәтиҗәләре буенча оешма эшчәнлегенә тикшерү акты рәсмиләштерелә, ул Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек органының вәкаләтле заты тарафыннан имзалана һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан раслана.

Тикшерү актында түбәндәгеләр күрсәтелә:
гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча белгечләр саны, аларның белем дәрәҗәсе һәм квалификациясе;
оешмага әзерлек узу өчен гариза белән мөрәҗәгать иткән гражданнар саны;
баланы гаиләгә алу мотивлары;
уңай бәяләмә һәм әзерлек узу турында таныклык алган гражданнар саны;
әзерлек узган һәм үз гаиләсенә бала алган гражданнар саны;
әзерлек узган гаиләләрдәге балаларны кире кайтару саны;

оешма эшчәнлегенең гражданнарны сайлау һәм әзерләү буенча сыйфатының гамәлдәге федераль һәм төбәк законнары таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләү;

гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү эшчәнлегенең сыйфатын һәм дәрәҗәсен бәяләүне исәпкә алып, оешманың алдагы эшчәнлеге мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр. Оешма эшчәнлегендә мәҗбүри таләпләрне яки җитешсезлекләрне бозу очраклары ачыкланган очракта, тикшерү актында ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча, аларны үтәү срокларын күрсәтеп, тәкъдимнәр күрсәтелә.

3.2. Тикшерү актын рәсмиләштерү срогы тикшерү башланганнан соң 10 календарь көн тәшкил итә.

3.3. Тикшерү акты 2 нөсхәдә рәсмиләштерелә, шуларның берсе оешма җитәкчесенә тикшерү акты расланганнан соң 3 көн эчендә җибәрелә, икенчесе –Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек органында саклана (Тәртипкә 2 номерлы кушымта).

3.4. Ачыкланган хокук бозулар очрагында оешма тикшерү акты белән билгеләнгән срокта аларны бетерү турында тәкъдимне үтәргә һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек органына, расланган документларны кушып, бозуларны бетерү турында хисап тапшырырга тиеш.

Тәртипкә 1 номерлы
кушымта

**Балигъ булмаган гражданнарның опекуннары яки попечительләре булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы оешманы яки,Россия Федерациясе гаилә законнарында билгеләнгән башка формаларда,ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә тәрбияләү өчен алган гаиләләрне планлы тикшерү графигы**

| Тикшерүләрнең даимилеге | Тикшерү үткәрү ае | Тикшерү үткәрү датасы | Тикшерү үткәрү вакыты |
|---|---|---|---|
| Елга 1 тапкыр | Ноябрь | Айның өченче атнасы | 1 көн |

Тәртипкә 2 номерлы
кушымта

**Балигъ булмаган гражданнарның опекуннары яки попечительләре булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча вәкаләтне гамәлгә ашыручы оешманы яки,Россия Федерациясе гаилә законнарында билгеләнгән башка формаларда,ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә тәрбияләү өчен алган гаиләләрне тикшерү акты**

Тикшерү актын төзү датасы_____________________________________________
Тикшерү уздыру көннәре саны, урыны һәм срогы ____________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________

Тикшерү төре һәм формасы______________________________________________
_______________________________________________________________________

Тикшерү үткәрергә нигез булганАлексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты карарының датасы һәм номеры __________________________________
_________________________________________________________________________Тикшерү үткәрелгән оешманың исеме____________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________

Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының тикшерүләр үткәрүчекомиссиясе әгъзалары (комиссия рәисен күрсәтеп)_________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________

Оешма тарафыннан тикшерү үткәрү өчен тапшырылган (тапшырылмаган) документлар (мәгълүмат)
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
____________________________________________________________

Опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда оешма эшчәнлегендә ачыкланган хокук бозу очраклары, аларның нинди булуы һәм эчтәлеге
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________

_______________________________________________________________

Оешма тарафыннан опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча ачыкланган хокук бозуларны һәм җитешсезлекләрне тикшерү тәмамланган датага бетерү турында мәгълүмат________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

___________________________________________________________________

Тикшерү нәтиҗәләре турында гомумиләштерелгән мәгълүмат һәм нәтиҗәләр

____________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______

Оешма җитәкчесенең тикшерү нәтиҗәләре белән танышу яки танышудан баш тартуы турында белешмә______________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________

Имзалар: